Шәһәр күләмендә география фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың йомгаклау этабы биремнәре
2024-2025 нче уку елы
10-11 нче сыйныф

Эш вакыты – 120 минут
Гомуми балл – 90

1. **Дөньяда иң салкын шәһәр нинди? (2 балл)**

а) Норильск (Россия)
б) Якутск (Росситя)
в) Йеллоунайф (Канада)
г) Улан-Батор (Монголия)
д) Фэрбанкс (АКШ)

2. **Зур шәһәр тирәсендә шәһәр яны зонасының үсешен һәм җәелеп китүен ничек атыйлар? (4 балл)**

_____

3. **Дөньяда иң танылган ярыш автомобильләрен кайсы предприятие җитештерә? (2 балл)**

а) Купер б) Вильямс в) Феррари г) Лотус

4. **Глобалистиканың фән буларак өйрәнә торган юнәлеше: (2 балл)**

а) литосфера, гидросфера, атмосфера һәм биосфераның үзара мөнәсәбәте
б) бөтендөнья сәяси картасының барлыкка килүе һәм үсеше
в) хәзерге этапта кешелек алдында торган дөньякүләм проблемалар
г) социаль-икътисадый үсешнең дөнякүләм әһәмияте

5. **Дөньяда иң эссе шәһәр нинди? (2 балл)**

а) Неллуру (Һиндстан) в)Томбукту (Мали)
б) Джибути (Джибути) г)Тирунелвели (Һиндстан)

6. **Саналып кителгән раслауларның кайсы дөрес түгел? (2 балл)**

а) атом-төш сугышының дөньякүләм куркынычы
б) үсеп килүче илләрнең артталыгы
в) дөньякүләм җәмәгатьчелекнең йомшак идарә ителеше
г) азык-төлек проблемасы

7. **Кайсы раслау дөрес түгел? (2 балл)**

а) Бөтендөнья океанын үзләштеү
б) эре елгаларның үзәннәрен үзләштерү
в) тигезсез рельефлы өлкәләрне үзләштерү

8. **Кайбер галимнәр моны глобаль проблемага санамыйлар (2 балл)**

а) антропоген б) табигать в) социаль

9. **Саналып киткән проблемаларның кайсы социаль характердагы проблемаларга керми? (2 балл)**

а) демографик
б) халык сәламәтлеге
в) экологик
г) урбанизация

10. **Беларусиядә җитештерелгән “Беларус” маркалы тракторлар ничә илгә сатыла? (2 балл)**

а) 29 б) 40 в) 20 г) 13

11. **Хәзерге Мексика территориясендә элекке заманда нинди цивилизацияләр яшәгән? (4 балл)**

_____

12. **Көньяк Америка гаучоларының киҗе-мамык һәм йоннан ясалган өскә ябыну киемнәре ничек атала? (4 балл)**

_____

13. **Испания дәүләтенең контурлы картасында 4 металлургия базасын “Fe” шартлы билгесе белән күрсәтергә: (8 балл)**

14. Табигый болыннар һәм милли парклар нинди хәлдә табигый ландшафтка мисал булып торалар? (2 балл)

а) практик яктан алар үзгәрмәсә
б) бик аз гына үзгәрсә
в) бик нык үзгәрсә
г) ясалма рәвештә үзгәрсә

15. Киң канатлы, төнлә генә оча торган имезүче хайванны христианнарның изге китабы – библиядә мактамыйлар; Һиндстанда аны "сазлык рухы" диләр; Кытайда исә аны "бәхет" дип атыйлар һәм изге кош, дип саныйлар. Бу нинди имезүче хайван? (4 балл)

_____

16. Ландшафтларны, аларның состав өлешләрен, аерым күренешләрен һәм үсешләрен барлыка килгәннән алып хәзерге көнгә кадәр өйрәнә торган юнәлеш принцибы ничек атала? (6 балл)

_____

17. Африка дәүләтенең мәйданы 11 мең кв. км. Биредә африкалылар һәм АКШ тан күчеп килгән негрлар яши (2%). Халкы исә 3 млн. кешедән артык. Шәһәр халкы 46 %. Рәсми тел – инглиз, диннәре – христиан, ислам һәм җирле диннәр. Әлеге дәүләт флагы астында Бөтендөнья океанында бик күп суднолар йөзә. Аграр ил. Халыкның тормыш дәрәҗәсе түбән.
Бу дәүләт һәм аның башкаласы ничек атала? (6 балл)

_____

18. Ел саен үтә торган халыкара ралли-марафонның исемен язып бетерегез: Париж - ... . Язылган шәһәрнең кайсы ил башкаласы булуын да язып куегыз. (4 балл)

_____

19. Индонезиядәге Малая архипелагының иң зур утравын ничек атыйлар? (6 балл)

_____

20. Әлегә милли парк АКШта урнашкан. Аңа 1872 елда дөньяда беренче милли парк буларак нигез салына. Мәйданы 9000 мең га чамасы. Кайнар чишмәләре һәм гейзерлары бик күп. Биредә ташка әверелгән агачлар да бар. Ылыслы урманнар тау болыннары белән алмашына. АКШ символы булган Ак башлы бөркет тә биредә үзенә оя кора.
АКШның әлеге милли паркы ничек атала? (6 балл)

_____

21. **Йөк ташу транспортында тонна-километр белән хисапланыла торган төп күрсәткечне ничек дип атыйлар? (4 балл)**

_____

22**. Сүз барган территория Кытайда аерым бер территория буларак билгеле. 1842 елда Бөекбритания аны Кытайдан тартып ала. Мәйданы бер мең кв. км. Халкы 6 миллионнан артык, 98% - кытайлар. Рәсми телләр - инглиз һәм кытай телләре. 1997 елда ул яңадан Кытайга күчте. Бөекбритания белән килешү нигезендә әлеге мәйданда 50 ел дәвамында андагы барлык шартлар электәгечә саклана. Ул эре промышленность, сәүдә һәм транспорт үзәге. Халыкның тормыш дәрәҗәсе бик югары.**
Кытайдагы әлеге аерым мәйдан ничек атала? (4 балл)

_____

23. **Буддизм дөньякүләм дин дип саналса да, индуизм һәм конфуций диннәре милли диннәр рәтендә генә тора.**
Моның сәбәбе нәрсәдә, дип уйлыйсыз? (10 балл)

_____
_____
_____
_____
_____
_____